**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**БОЕРЫГЫ**

06.09.2024

№ 302

**2024–2028 елларга Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны янгынга каршы әзерләү планын раслау турында**

Россия Федерациясе Урман кодексының $53^1$ статьясының 13 өлеше, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урманчылык территориясендә урманнарны янгынга каршы әзерләү планын эшләү һәм раслау кагыйдәләрен һәм аның формасын, Россия Федерациясе субъекты территориясендә урманнарны янгынга каршы әзерләү планын эшләү кагыйдәләрен һәм аның формасын раслау турында» 2023 елның 27 декабрендәге 2332 номерлы карары, «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясының $6^2$ пункты нигезендә, Федераль урман хуҗалыгы агентлыгының уңай бәяләмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы территориясендә урман янгыннарын кисәтү максатларында:

1. 2024–2028 елларга Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны янгынга каршы әзерләү планын (кушымтада бирелә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына, законнарда билгеләнгән очракларда, әлеге боерык белән расланган 2024–2028 елларга Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны янгынга каршы әзерләү планына үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәрне билгеләнгән тәртиптә вакытында тапшыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2024 елның « 06 » сентябрендәге
302 номерлы боерыгы белән
расланды

2024–2028 елларга Татарстан Республикасы территориясендә
урманнарны янгынга каршы әзерләү
ПЛАНЫ

# I. Татарстан Республикасына кыскача бәяләмә

## 1.1. Рельефы, гидрографиясе, климаты, туфрак-грунт шартлары турында мәгълүмат

Татарстан Республикасы Көнчыгыш-Европа тигезлегенең көнчыгышында, ике зур елга – Идел белән Кама елгалары арасында төньяк киңлектәге 47° һәм 54° һәм көнчыгыш озынлыгының 54° һәм 57° арасында урнашкан. Татарстан Республикасының башкаласы – Казан шәһәре Мәскәү шәһәреннән көнчыгышка таба 797 км ераклыкта урнашкан.

Республиканың гомуми мәйданы 6783,7 мең гектар (67,8 мең кв. км яисә Россия Федерациясе территориясенең якынча 0,4 процентын һәм Идел буе федераль округы территориясенең якынча 7 процентын) тәшкил итә. Территориянең буйга максималь озынлыгы – төньяктан көньякка 290 км һәм көнбатыштан көнчыгышка 460 км. Татарстан Республикасы чит ил дәүләтләре белән чиктәш түгел.

Татарстан Республикасының территориясе елга үзәнлекләренең куе челтәрләре белән тармакланган калкулыклы киртләч яссылыктан гыйбарәт. Әлеге яссылык Идел һәм Кама елгаларының киң үзәнлекләре белән өч өлешкә бүленә: Идел алды, Кама алды һәм Кама аръягы. Максималь биеклеге 276 метр булган Идел алды Идел буе калкулыгының төньяк-көнчыгыш өлешен алып тора. Көнчыгыш Кама алдына төньяктан Иж елгасы үзәнлеге белән аерылган Можга һәм Сарапул калкулыкларының көньяк очлыклары кереп тора. Иң биек урыннар биредә 243 метрга кадәр җитә. Көнчыгыш Кама аръягындагы Бөгелмә калкулыгы Татарстан Республикасында иң биеге булып санала (381 метрга кадәр). Иң тәбәнәк рельеф Көнбатыш Кама аръягына хас (нигездә 200 метрга кадәр).

Туфрак күп төрле булуы белән аерылып тора – төньякта һәм көнбатышта соры урман һәм көлсу туфрактан алып республиканың көньягында кара туфракның төрле төрләренә кадәр. Татарстан Республикасы территориясендә өч туфрак районын аерып чыгаралар:

а) Төньяк (Кама алды) – ачык соры урман (29 процент) һәм кәсле-көлсу (21 процент) туфрак аеруча таралган, төп рәвештә субүләр платоларда һәм тау битләренең югарыгы өлешләрендә урнашкан. 18,3 процентын соры һәм куе соры урман туфрагы алып тора. Калкулыкларда һәм үрләрдә кәсле туфраклар очрый. 22,5 процентын юдырылган туфраклар били, тугай туфраклары – 6–7 процент, сазлык җире – якынча 2 процент. Кайбер районнарда (Балтач, Кукмара, Мамадыш) эрозия көчле, территориянең 40 процентына кадәр дучар ителгән.

б) Көнбатыш (Идел алды) – төньяк өлешендә урман-дала (51,7 процент), соры һәм куе соры (32,7 процент) туфраклары өстенлек итә. Мәйданның зур өлешен көлсуланган һәм селтеле кара җирләр били. Районның югары өлешләрендә ачык соры һәм кәсле-көлсу туфрак ята (12 процент). Тугай

туфрагы – 6,5 процент, сазлык җирләре 1,2 процентын алып тора. Районның көньяк-көнбатышында кара җирләр таралган (селтеле туфраклар өстенлек итә);

в) Көньяк-көнчыгыш (Кама аръягы) – Чишмә елгасыннан көнбатышка таба селтеле һәм гади кара туфрак өстенлек итә, Кече Чирмешән елгасының уң як яр буе куе соры туфрактан тора. Чишмә елгасыннан көнчыгышка таба соры урман һәм кара туфраклар өстенлек итә, районның төньяк өлеше – селтеле кара туфрак. Калкулыкларда урман-дала туфрагы ята, иңкүлекләрдә – кара җир.

Татарстан Республикасын төрле максатларда су ресурслары белән тәэмин итүче иң зур су объектлары – 4 сусаклагыч:

а) Куйбышев – 1955 елда төзелгән, Татарстан Республикасында гына түгел, ә Европада да иң зурысы, Урта Иделдән агып төшкән суны сезонга карап көйләп тора;

б) Түбән Кама – 1978 елда төзелгән һәм гидроузелга тәүлеклек һәм атналык су бүлүне тәэмин итә;

в) Зәй – 1963 елда төзелгән, ГРЭСны техник тәэмин итү өчен хезмәт итә;

г) Карабаш – 1957 елда төзелгән, нефть чыгару һәм сәнәгать предприятиеләрен су белән тәэмин итү өчен хезмәт итә.

Республика территориясендә 731 гидротехник корылма, 550 буа, 115 чистарту корылмасы, 11 саклык дамбасы бар.

Республика чикләрендә климаттагы аермалыклар чагыштырмача зур түгел. Территория буенча җылы чорның озынлыгы – 198–209 көн, салкын чор 156-167 көн тирәсе тәшкил итә. Диңгез һәм океан йогынтысыннан ерак булганлыктан, республика территориясе һава массаларының көнбатыш күчешенең кимүе һәм климатның континентальлеге көчәю белән характерлана. Бу исә кышның озынаюы, күчеш чорының кимүе, җәй башында һәм җәй ахырында салкынайту куркынычы артуда чагылыш таба. Уртача тәүлеклек һава температурасы +5°С тамгасын язын апрель уртасында, ә көзен октябрь урталарында уза. Беренче кырау 10–28 сентябрьдә, соңгысы 10–21 майда күзәтелә. Температураның +10°С тамгасын узып тотрыклы урнашуы язын май аеның беренче декадасына, көзен сентябрьнең икенче декадасына туры килә. Язгы соңгы кырау һәм көзге беренче кырау даталары арасындагы салкын төшмәгән чорның уртача дәвамлылыгының территория буенча үзгәрүе киң колач ала – 106 көннән 150 көнгә кадәр дәвам итә.

## 1.2. Транспорт һәм урман инфраструктурасы объектлары, урманнарны янгыннан саклау максатларында аларны куллану мөмкинлекләре турында мәгълүмат, елгалар һәм сулыклар, урманнарны янгыннан саклау өчен аларны куллану мөмкинлеге турында мәгълүмат, икътисадның катнаш тармакларының урманда пирологик хәлне үстерүгә йогынтысын бәяләү

Татарстан Республикасында транспорт хуҗалыкның төп тармакларының берсе, җитештерү һәм социаль инфраструктураның мөһим состав өлеше булып тора. Транспорт коммуникацияләре системасы төбәкнең территориаль бөтенлеге, аның икътисадый пространствосы бердәмлеге

шарты булып тора. Ул Татарстан Республикасын Россиянең башка төбәкләре, дөнья җәмәгатьчелеге белән бәйли, төбәкнең глобаль икътисадый системага кушылуын тәэмин итү нигезе булып тора. Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары, тимер юллар һәм линияле объектларның урман фондын җәелдерүе, шулай ук урман юллары, квартал ызаннары рәвешендәге яхшы үсеш алган урман инфраструктурасының булуы урманнарны янгыннан саклау чараларын күрү мөмкинлеген тәэмин итә.

Иң зур елгалар – Идел (республика территориясе буйлап 177 км) һәм Кама (380 км), шулай ук елганың ике кушылдыгы – Нократ (60 км) һәм Агыйдел (50 км), елына гомуми 234 млрд.куб метр агымсу (барлык елгаларның гомуми агымында 97,5 процент) тәэмин итә. Болардан тыш, республика территориясе буйлап якынча тагын 500 кечкенә елга һәм күпсанлы инешләр ага. Су ресурларының бик күп запасы зур ике объектка – Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларында тупланган. Республикада шулай ук 8 меңнән артык зур булмаган күл һәм буа исәпләнә.

Татарстан Республикасы Россия Федерациясенең эре индустриаль районы үзәгендә, илнең көнчыгышын, көнбатышын, төньягын һәм көньягын тоташтыручы мөһим магистральләр кисешкән урында урнашкан. Татарстан Республикасы зур икътисадый потенциалга һәм үсеш алган кеше капиталына ия. Татарстанның конкурент өстенлекләре булып уңайлы географик урыны, бай табигый ресурслары, югары квалификацияле хезмәт ресурслары, көчле сәнәгать һәм фәнни комплексы, үсеш алган транспорт инфраструктурасы тора. Татарстан Республикасының сәнәгать профилен нефть-газ химиясе комплексы, конкурентлыкка сәләтле продукция җитештерүче эре машина төзелеше предприятиеләре, шулай ук электр һәм радио приборлары төзелеше билгели. Татарстан Республикасы – югары интенсив авыл хуҗалыгы җитештерү төбәге. Республиканың авыл хуҗалыгы халыкның төп азык-төлеккә ихтыяҗын канәгатьләндерә, конкурентлы продукция җитештерү арта, авыл хуҗалыгы чималларын эшкәртү өлеше арта, агросәнәгать комплексы өлкәсендә эшкуарлыкны үстерүне стимуллаштыру чаралары гамәлгә ашырыла, югары сыйфат стандартларына туры килгән тирәнтен эшкәртелгән продукция җитештерелә.

### 1.3. Татарстан Республикасы территориясендә урман фонды турында мәгълүмат – урман үсемлекләре зоналары һәм урман районнары, урманнар таралышы, урманнарның гомуми мәйданы һәм аны урманчылыклар буенча бүлү, урманнарны максатчан билгеләнеше, иң күп таралган токымнары, яшь төркемнәре буенча бүлү, урман районнары (урман зоналары) буенча иң күп таралган урман төрләре

Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Россия Федерациясе урман үсемлекләре зоналары исемлеген һәм Россия Федерациясе урман районнары исемлеген раслау турында» 2014 елның 18 августындагы 367 номерлы боерыгы белән

расланган Россия Федерациясе урман районнары исемлеге нигезендә Татарстан Республикасы территориясе Россия Федерациясенең Европа өлешендәге урман-дала районына һәм Россия Федерациясенең Европа өлешендәге ылыслы-киң яфраклы (катнаш) урманнар районына кертелгән. Урман районнарының визуаль чиге Идел, Кама, Шилнә елгалары буйлап уза, республиканы көнбатыштан көнчыгышка таба су киңлеге ярдәмендә урман районнарына бүлә.

Татарстан Республикасында урманнарның гомуми таралышы 17,4 процент тәшкил итә.

Урман фондының гомуми мәйданы 1226309 гектар тәшкил итә, шул исәптән урманчылыклар буенча: Әгерҗе – 45245 гектар, Азнакай – 45701 гектар, Аксубай – 29637 гектар, Әлки – 37364 гектар, Әлмәт – 49966 гектар, Арча – 31989 гектар, Баулы – 22766 гектар, Биләр – 50555 гектар, Болгар – 18667 гектар, Бөгелмә – 43590 гектар, Буа – 18376 гектар, Алабуга – 28661 гектар, Зәй – 58867 гектар, Зеленодольск – 26188 гектар, Ары – 16981 гектар, Кайбыч – 25102 гектар, Кәләй – 40990 гектар, Кама – 54059 гектар, Кызыл Йолдыз – 42336 гектар, Лаеш – 33256 гектар, Лениногорск – 52983 гектар, Лубян – 12994 гектар, Мамадыш – 465570 гектар, Минзәлә – 71378 гектар, Түбән Кама – 42772 гектар, Нурлат – 89109 гектар, Идел буе – 27903 гектар, Шәһәр яны – 28588 гектар, Саба – 60006 гектар, Тәтеш – 37234 гектар, Чирмешән – 36489 гектар.

Урманнарның максатчан билгеләнеше буенча бүленеше түбәндәгечә: саклагыч урманнар – 554,9 мең гектар – 45,2 процент, файдаланыла торган урманнар – 671,4 мең гектар – 54,8 процент.

Урманнарның иң күп таралган токымнар буенча бүленеше түбәндәгечә: усак – 237,3 мең гектар, юкә – 227 мең гектар, каен – 201,6 мең гектар, нарат – 180,1 мең гектар, имән – 158,7 мең гектар, чыршы – 68,5 мең гектар.

Яшь төркемнәре буенча урманнар түбәндәгечә бүленгән: яшь үсентеләр – 205,5 мең гектар – 17,9 процент, урта яшьтәге – 400,7 мең гектар – 34,8 процент, өлгереп килүче – 185,6 мең гектар – 16,2 процент, өлгергән һәм картайган – 358 мең гектар – 31,1 процент.

### 1.4. Файдалануга бирелгән урман кишәрлекләре турында мәгълүмат, – урманнарны янгыннан саклауны да кертеп, файдалануга бирелгән урман хуҗалыгы кишәрлекләрендә (урнашкан урыннарын күрсәтеп) урман хуҗалыгы эшчәнлегенә бәяләмә, 2024–2028 елларга планлаштырыла торган үсеш юнәлешләре һәм күләмнәре

Файдалануга бирелгән урман кишәрлекләрендә урманнарны янгынга каршы әзерләү чараларын үткәрү урманнардан файдаланучы затлар тарафыннан урманнарны үзләштерү проектлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2024 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы территориясендәге урман фондында урманнардан файдаланучы затлар тарафыннан 304,9 мең

гектар мәйдандагы урман кишәрлекләрен арендалау, даими (вакытын чикләмичә) файдалану, түләүсез нигездә файдалану буенча 2404 шартнамә төзелгән, шул исәптән 60,2 мең гектар мәйдандагы урман кишәрлекләрен арендалау буенча – 9 шартнамә.

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Урман планын раслау турында» 2018 елның 24 декабрендәге ПУ-880 номерлы Указы (алга таба – Татарстан Республикасы Урман планы) белән расланган Татарстан Республикасы Урман планы нигезендә, шулай ук урманнарны үзләштерү проектлары нигезендә агач материалы әзерләү өчен файдалануга бирелгән урман кишәрлекләрендә 123,6 км күләмендә янгынга каршы минераллаштырылган полосалар ясау, 291,5 км күләмендә янгынга каршы минераллаштырылган полосаларны чистарту һәм яңарту, 10,6 км күләмендә урманнарны янгыннан саклау өчен билгеләнгән урман юлларын эксплуатацияләү планлаштырылган.

Файдалануга бирелгән урман кишәрлекләре турында мәгълүмат, файдалануга бирелгән урман кишәрлекләрендәге урман хуҗалыгы эшчәнлегенә сыйфатлама (аларның урнашу урынын күрсәтеп), урманнарны янгыннан саклауны, 2024–2028 елларга планлаштырылган юнәлешләрне һәм үсеш күләмнәрен кертеп, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы боерыклары белән расланды, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Урман хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтта урнаштырылган Татарстан Республикасы урманчылыклары территориясендә урманнарны янгынга каршы әзерләү планнарында чагылдырылды.

## 1.5. Урманнарны янгынга каршы әзерләү торышы турында мәгълүмат (урманнарны янгынга каршы әзерләү объектларының булуы һәм урманнарны янгынга каршы әзерләү чараларының нәтиҗәлелеген бәяләү)

Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны янгынга каршы әзерләү буенча чаралар исемлеге һәм күләмнәре Татарстан Республикасының Урман планында билгеләнгән.

Татарстан Республикасы территориясендәге урман фонды җирләрендә 2023 елда Россия Федерациясе законнары нигезендә, шул исәптән Техник җайга салу һәм метрология буенча федераль агентлыкның 2017 елның 21 ноябрендәге 1792-ст номерлы боерыгы белән расланган «Урманнарны янгынга каршы әзерләү объектлары. Гомуми таләпләр» ГОСТ Р 57972-2017 Россия Федерациясе илкүләм стандарты нигезендә башкарылган түбәндәге урманнарны янгынга каршы әзерләү объектлары бар:

- янгынга каршы минераллаштырылган полоса – 2395,2 км;
- урманнарны янгыннан саклау өчен билгеләнгән юл – 111,3 км;
- урманнарда янгын куркынычсызлыгы чаралары турында мәгълүмат булган стенд, билге һәм күрсәткеч – 794 данә;

- урманнарда булучы гражданнарның ял итү зонасы – 225 данә;
- янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында гражданнарның урманнарда булуын чикләүне тәэмин итә торган шлагбаум – 398 данә;
- янгынга каршы сулык һәм янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганагына керү – 55 данә.

Урманнарны янгынга каршы әзерләү объектлары канәгатьләнерлек хәлдә.

## II. Үтәү чыгымнарын исәпкә алып, урманнарны янгынга каршы әзерләүнең проектлана торган чаралары

Урманнарны саклау буенча дәүләт эшләрен башкаруга (хезмәтләрен күрсәтүгә) чыгымнар нормативларын исәпләү Федераль урман хуҗалыгы агентлыгының «Урманнарны саклау, яклау, торгызу, урман үрчетү һәм урманнарны әзерләү буенча дәүләт эшләрен башкаруга (хезмәтләрен күрсәтүгә) чыгымнар нормативларын раслау турында һәм Федераль урман хуҗалыгы агентлыгының 2019 елның 19 июнендәге 762 номерлы боерыгының үз көчен югалтуын тану хакында» 2020 елның 29 июнендәге 607 номерлы боерыгы нигезендә гамәлгә ашырылды.

Әлеге план гамәлдә булган чорга ел саен янгынга каршы чаралар уздыру Татарстан Республикасы Урман планы нигезендә планлаштырылган.

### 2.1. Урманнарны янгыннан саклау өчен билгеләнгән урман юлларын төзү, карап тоту һәм эксплуатацияләү

Урманнарны янгыннан саклау өчен урман юлларын төзү түбәндәгечә планлаштырылган:

2024 елга 111,3 км күләмендә, үтәү чыгымнары – 11687,6 мең сум;
2025 елга 111,3 км күләмендә, үтәү чыгымнары – 11687,6 мең сум;
2026 елга 111,3 км күләмендә, үтәү чыгымнары – 11688,0 мең сум;
2027 елга 111,3 км күләмендә, үтәү чыгымнары – 11688,0 мең сум;
2028 елга 111,3 км күләмендә, үтәү чыгымнары – 11688,0 мең сум.

Урманнарны янгыннан саклау өчен билгеләнгән урман юлларын карап тоту түбәндәгечә планлаштырыла:

2024 елга 426,5 км күләмендә, үтәү чыгымнары – 4755,5 мең сум;
2025 елга 426,5 км күләмендә, үтәү чыгымнары – 4751,2 мең сум;
2026 елга 426,5 км күләмендә, үтәү чыгымнары – 4694,9 мең сум;
2027 елга 426,5 км күләмендә, үтәү чыгымнары – 4694,9 мең сум;
2028 елга 426,5 км күләмендә, үтәү чыгымнары – 4694,9 мең сум.

Урманнарны янгыннан саклау өчен билгеләнгән урман юлларын эксплуатацияләү түбәндәгечә планлаштырыла:

2024 елга 8964,6 км күләмендә, үтәү чыгымнары – 35858,4 мең сум;
2025 елга 9075,9 км күләмендә, үтәү чыгымнары – 36342,1 мең сум;
2026 елга 9187,2 км күләмендә, үтәү чыгымнары – 36843,0 мең сум;

2027 елга 9298,5 км күләмендә, үтәү чыгымнары – 37289,3 мең сум;
2028 елга 9409,8 км күләмендә, үтәү чыгымнары – 37735,6 мең сум.

### 2.2. Урманнарны янгыннан саклау буенча авиация эшләрен башкару максатларында файдаланыла торган самолетлар һәм вертолетлар өчен утырту мәйданчыклары булдыру, карап тоту һәм алардан файдалану

Татарстан Республикасы территориясендә урман фонды җирләрендә урманнарны янгыннан саклау буенча авиация эшләрен башкару максатларында файдаланыла торган самолетлар һәм вертолетлар өчен утырту мәйданчыклары булдыру, карап тоту һәм эксплуатацияләү планлаштырылмый.

### 2.3. Урманда ызан юлларын салу, янгынга каршы аралыклар ясау, янгынга каршы минераллаштырылган полосалар салу

Татарстан Республикасы территориясендәге урман фонды җирләрендә урманның ызан юлларын ясау, янгынга каршы аралыклар казу планлаштырылмый.

Янгынга каршы минераллаштырылган полосалар урнаштыру түбәндәгечә планлаштырылган:

2024 елга 2395,2 км күләмендә, үтәү чыгымнары – 5593,4 мең сум;
2025 елга 2395,2 км күләмендә, үтәү чыгымнары – 5593,4 мең сум;
2026 елга 2395,2 км күләмендә, үтәү чыгымнары – 5574,7 мең сум;
2027 елга 2395,2 км күләмендә, үтәү чыгымнары – 5574,7 мең сум;
2028 елга 2395,2 км күләмендә, үтәү чыгымнары – 5574,7 мең сум.

### 2.4. Янгын күзәтчелеге пунктларын (каланчалар, мачталар, павильоннар һәм башка күзәтү пунктлары), янгынга каршы инвентарь туплау пунктларын төзү, карап тоту һәм эксплуатацияләү

Янгын күзәтчелеге пунктларын (каланчалар, мачталар, павильоннар һәм башка күзәтү пунктлары), янгынга каршы инвентарь туплау пунктларын төзү, карап тоту һәм эксплуатацияләү түбәндәгечә планлаштырыла:

2024 елга 16 данә күләмендә, башкару чыгымнары – 160 мең сум;
2025 елга 16 данә күләмендә, башкару чыгымнары – 160 мең сум;
2026 елга 16 данә күләмендә, башкару чыгымнары – 165 мең сум;
2027 елга 16 данә күләмендә, башкару чыгымнары – 165 мең сум;
2028 елга 16 данә күләмендә, башкару чыгымнары – 165 мең сум.

## 2.5. Янгын сүндерү сулыкларыннан һәм янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларына керү юлларыннан файдалану

Татарстан Республикасы территориясендәге урман фонды җирләрендә янгынга каршы сулыклар һәм янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларына керү юлларын төзү планлаштырылмый.

## 2.6. Җирләрне гидромелиорацияләү буенча эшләр башкару

Татарстан Республикасы территориясендә урман фонды җирләрендә җирләрне гидромелиорацияләү буенча эшләр башкару планлаштырылмый.

## 2.7. Урман үсентеләренең токым составын җайга салу юлы белән урманнарның табигый янгын куркынычын киметү

Татарстан Республикасы территориясендәге урман фонды җирләрендәге урман утыртмаларының токым составын җайга салу юлы белән урманнарның табигый янгын куркынычын киметү планлаштырылмый.

## 2.8. Яндыруның куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын, территориаль урнашуын, мәйданының күләмнәре турындагы мәгълүматны да кертеп, чыбык-чабыкны, урман түшәмәсен, коры үләнне һәм башка янучан урман материалларын контрольдә тотып, профилактик яндыруны уздыру

Татарстан Республикасы территориясендә урман фонды җирләрендә, яндыруның куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын, территориаль урнашуын, мәйданының күләмнәре турындагы мәгълүматны да кертеп, чыбык-чабыкны, урман түшәмәсен, коры үләнне һәм башка янучан урман материалларын контрольдә тотып, профилактик яндыру уздыру планлаштырылмый.

## 2.9. Урманда ызан юлларын чистарту, янгынга каршы минераллаштырылган полосаларны чистарту һәм аларны яңарту

Татарстан Республикасы территориясендәге урман фонды җирләрендәге ызан юлларын чистарту планлаштырылмый.

Янгынга каршы минераллаштырылган полосаларны чистарту һәм аларны яңарту түбәндәгечә планлаштырыла:

2024 елга 4806,9 км күләмендә, үтәү чыгымнары – 4978,3 мең сум;
2025 елга 4806,9 км күләмендә, үтәү чыгымнары – 4955,7 мең сум;
2026 елга 4806,9 км күләмендә, үтәү чыгымнары – 4875,4 мең сум;
2027 елга 4967,9 км күләмендә, үтәү чыгымнары – 5038,7 мең сум;
2028 елга 4967,9 км күләмендә, үтәү чыгымнары – 5037,7 мең сум.

## 2.10. Янгынга каршы сулыкларны һәм су белән тәэмин итү чыганакларына килү юлларын эксплуатацияләү

Янгынга каршы сулыкларны һәм су белән тәэмин итү чыганакларына килү юлларын эксплуатацияләү түбәндәгечә планлаштырыла:
2024 елга 55 данә күләмендә, башкару чыгымнары – 220 мең сум;
2025 елга 55 данә күләмендә, башкару чыгымнары – 220 мең сум;
2026 елга 55 данә күләмендә, башкару чыгымнары – 250 мең сум;
2027 елга 55 данә күләмендә, башкару чыгымнары – 250 мең сум;
2028 елга 55 данә күләмендә, башкару чыгымнары – 250 мең сум.

## 2.11. Россия Федерациясе Урман кодексының 11 статьясы нигезендә урманнарда гражданнар ял итә торган зоналарны әзерләү

Россия Федерациясе Урман кодексының 11 статьясы нигезендә урманнарда гражданнар ял итә торган зоналарны әзерләү түбәндәгечә планлаштырыла:
2024 елга 225 данә күләмендә, башкару чыгымнары – 900 мең сум;
2025 елга 225 данә күләмендә, башкару чыгымнары – 900 мең сум;
2026 елга 225 данә күләмендә, башкару чыгымнары – 950 мең сум;
2027 елга 225 данә күләмендә, башкару чыгымнары – 950 мең сум;
2028 елга 225 данә күләмендә, башкару чыгымнары – 950 мең сум.

## 2.12. Шлагбаумнар кую һәм эксплуатацияләү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, урманнарда гражданнарның булуын чикләүне тәэмин итәрлек киртәләр кору

Шлагбаумнар кую һәм эксплуатацияләү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, урманнарда гражданнарның булуын чикләүне тәэмин итәрлек киртәләр кору түбәндәгечә планлаштырыла:
2024 елга 398 данә күләмендә, башкару чыгымнары – 1990 мең сум;
2025 елга 398 данә күләмендә, башкару чыгымнары – 1990 мең сум;
2026 елга 398 данә күләмендә, башкару чыгымнары – 2000 мең сум;
2027 елга 398 данә күләмендә, башкару чыгымнары – 2000 мең сум;
2028 елга 398 данә күләмендә, башкару чыгымнары – 2000 мең сум.

## 2.13. Янгынга каршы ышыклар булдыру һәм аларны карап тоту, яфраклы кырпулар урнаштыру

Татарстан Республикасы территориясендәге урман фонды җирләрендә янгынга каршы ышыклар булдыру, аларны карап тоту һәм яфраклы кырпулар урнаштыру планлаштырылмый.

## 2.14. Урманнарда янгын куркынычсызлыгы чаралары турында мәгълүматы булган стендлар һәм башка тамгалар урнаштыру

Урманнарда янгын куркынычсызлыгы чаралары турында мәгълүматы булган стендлар һәм башка тамгалар урнаштыру түбәндәгечә планлаштырыла:

2024 елга 794 данә күләмендә, башкару чыгымнары – 2300 мең сум;
2025 елга 794 данә күләмендә, башкару чыгымнары – 2300 мең сум;
2026 елга 794 данә күләмендә, башкару чыгымнары – 2400 мең сум;
2027 елга 794 данә күләмендә, башкару чыгымнары – 2400 мең сум;
2028 елга 794 данә күләмендә, башкару чыгымнары – 2400 мең сум.

## 2.15. Проектлана торган чараларның күләме һәм объектлар буенча бүленеше

Урманчылыклар киселешендә 2024–2028 елларга проектлана торган чараларны объектлар буенча бүлү турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы боерыгы белән расланды, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылган Татарстан Республикасы урманчылыклары территориясендә урманнарны янгынга каршы әзерләү планнарында чагылдырылган.

# 2024 елга урманчылыклар буенча проектлана торган чаралар күләме

| Т/с | Урманчылык атамасы | Урманнарны янгыннардан саклау өчен билгеләнгән урман юллары төзү, км | Урманнарны янгыннан саклау өчен билгеләнгән урман юлларын карап тоту, км | Урманнарны янгыннардан саклау өчен билгеләнгән урман юлларын эксплуатацияләү, км | Янгынга каршы минераллаштырылган полосалар урнаштыру, км | Янгын күзәтчелеге пунктларын (каланчалар, мачталар, павильоннар һәм башка күзәтү пунктлары), янгынга каршы инвентарь туплау пунктларын төзү, карап тоту һәм эксплуатацияләү, данә | Янгынга каршы минераллаштырылган полосаларны чистарту һәм аларны яңарту, км | Янгынга каршы сулыкларны һәм су белән тәэмин итү чыганакларына килү юлларын эксплуатацияләү, данә | Россия Федерациясе Урман кодексының 11 статьясы нигезендә урманнарда гражданнар ял итә торган зоналарны әзерләү, данә | Шлагбаумнар кую һәм эксплуатацияләү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, урманнарда гражданнарның булуын чикләүне тәэмин итәрлек киртәләр кору, данә | Урманнарда янгын куркынычсызлыгы чаралары турында мәгълүматы булган стендлар һәм башка тамгалар урнаштыру, данә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Әгерҗе | 4,1 | 15,7 | 331,0 | 100,0 | 2 | 235,0 | 1 | 8 | 15 | 29 |
| 2 | Азнакай | 4,1 | 15,9 | 334,3 | 20,0 | - | 119,5 | 2 | 8 | 15 | 30 |
| 3 | Аксубай | 2,7 | 11,3 | 216,1 | 39,0 | - | 185,0 | 1 | 5 | 10 | 19 |
| 4 | Әлки | 3,4 | 13,0 | 274,1 | 50,0 | - | 89,0 | 2 | 7 | 12 | 24 |
| 5 | Әлмәт | 4,5 | 17,3 | 363,8 | 40,0 | - | 169,0 | - | 9 | 16 | 32 |
| 6 | Арча | 2,9 | 11,1 | 232,9 | 100,0 | - | 181,0 | 1 | 6 | 10 | 21 |
| 7 | Баулы | 2,1 | 8,0 | 168,7 | 83,0 | - | 224,9 | - | 4 | 7 | 15 |
| 8 | Биләр | 4,6 | 17,5 | 368,4 | 96,0 | - | 290,0 | 1 | 9 | 16 | 33 |
| 9 | Болгар | 1,7 | 6,5 | 136,0 | 10,0 | - | 63,0 | 1 | 3 | 6 | 12 |
| 10 | Бөгелмә | 4,0 | 15,2 | 320,1 | 169,0 | - | 197,0 | 1 | 8 | 14 | 28 |
| 11 | Буа | 1,7 | 6,4 | 135,1 | 30,0 | - | 144,0 | - | 3 | 6 | 12 |
| 12 | Алабуга | 2,6 | 10,9 | 209,0 | 149,0 | - | 110,0 | 1 | 5 | 9 | 19 |
| 13 | Зәй | 5,3 | 19,3 | 427,0 | 36,0 | - | 165,0 | 6 | 11 | 19 | 38 |
| 14 | Зеленодольск | 2,4 | 9,1 | 191,0 | 199,0 | 3 | 213,0 | 2 | 6 | 8 | 17 |
| 15 | Ары | 1,5 | 5,9 | 123,5 | 198,2 | 1 | 85,0 | 1 | 3 | 5 | 11 |
| 16 | Кайбыч | 2,3 | 9,7 | 182,9 | 105,0 | - | 120,0 | 2 | 5 | 8 | 16 |
| 17 | Кәләй | 3,7 | 14,3 | 299,5 | 20,0 | - | 70,0 | 3 | 8 | 13 | 27 |
| 18 | Кама | 4,9 | 18,8 | 394,6 | 100,0 | 1 | 171,0 | 3 | 10 | 18 | 35 |
| 19 | Кызыл Йолдыз | 3,8 | 14,7 | 308,2 | 13,0 | - | 98,0 | 2 | 8 | 14 | 27 |
| 20 | Лаеш | 3,0 | 11,6 | 243,2 | 149,0 | 1 | 239,0 | 2 | 6 | 11 | 22 |
| 21 | Лениногорск | 4,8 | 19,4 | 385,8 | 50,0 | - | 134,0 | 3 | 10 | 17 | 34 |
| 22 | Лубян | 1,2 | 4,5 | 94,5 | 10,0 | 2 | 34,0 | - | 2 | 4 | 8 |
| 23 | Мамадыш | 4,3 | 16,5 | 346,9 | 160,0 | 1 | 140,0 | 2 | 9 | 15 | 31 |
| 24 | Минзәлә | 6,5 | 25,0 | 525,3 | 30,0 | - | 273,0 | 1 | 13 | 23 | 47 |
| 25 | Түбән Кама | 3,9 | 15,0 | 315,6 | 81,0 | 1 | 290,0 | 2 | 8 | 14 | 28 |
| 26 | Нурлат | 5,6 | 19,8 | 649,1 | 118,0 | 1 | 120,0 | 1 | 16 | 29 | 56 |
| 27 | Идел буе | 2,5 | 9,7 | 203,1 | 35,0 | - | 86,0 | 6 | 5 | 9 | 18 |
| 28 | Шәһәр яны | 5,0 | 16,0 | 208,5 | 119,0 | 2 | 224,5 | 1 | 5 | 12 | 18 |
| 29 | Саба | 5,5 | 20,9 | 439,2 | 36,0 | 1 | 92,0 | 2 | 11 | 19 | 39 |
| 30 | Тәтеш | 3,4 | 14,9 | 271,5 | 20,0 | - | 122,0 | 1 | 7 | 12 | 24 |
| 31 | Чирмешән | 3,3 | 12,6 | 265,7 | 30,0 | - | 123,0 | 4 | 7 | 12 | 24 |
| Урманчылыклар буенча барлыгы | | 111,3 | 426,5 | 8964,6 | 2395,2 | 16 | 4806,9 | 55 | 225 | 398 | 794 |

# 2025 елга урманчылыклар буенча проектлана торган чаралар күләме

| Т/с | Урманчылык атамасы | Урманнарны янгыннардан саклау өчен билгеләнгән урман юллары төзү, км | Урманнарны янгыннан саклау өчен билгеләнгән урман юлларын карап тоту, км | Урманнарны янгыннардан саклау өчен билгеләнгән урман юлларын эксплуатацияләү, км | Янгынга каршы минераллаштырылган полосалар урнаштыру, км | Янгын күзәтчелеге пунктларын (каланчалар, мачталар, павильоннар һәм башка күзәтү пунктлары), янгынга каршы инвентарь туплау пунктларын төзү, карап тоту һәм эксплуатацияләү, данә | Янгынга каршы минераллаштырылган полосаларны чистарту һәм аларны яңарту, км | Янгынга каршы сулыкларны һәм су белән тәэмин итү чыганакларына килү юлларын эксплуатацияләү, данә | Россия Федерациясе Урман кодексының 11 статьясы нигезендә урманнарда гражданнар ял итә торган зоналарны әзерләү, данә | Шлагбаумнар кую һәм эксплуатацияләү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, урманнарда гражданнарның булуын чикләүне тәэмин итәрлек киртәләр кору, данә | Урманнарда янгын куркынычсызлыгы чаралары турында мәгълүматы булган стендлар һәм башка тамгалар урнаштыру, данә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Әгерҗе | 4,1 | 15,7 | 335,1 | 100,0 | 2 | 235,0 | 1 | 8 | 15 | 29 |
| 2 | Азнакай | 4,1 | 15,9 | 338,4 | 20,0 | - | 119,5 | 2 | 8 | 15 | 30 |
| 3 | Аксубай | 2,7 | 11,3 | 218,8 | 39,0 | - | 185,0 | 1 | 5 | 10 | 19 |
| 4 | Әлки | 3,4 | 13,0 | 277,5 | 50,0 | - | 89,0 | 2 | 7 | 12 | 24 |
| 5 | Әлмәт | 4,5 | 17,3 | 368,3 | 40,0 | - | 169,0 | - | 9 | 16 | 32 |
| 6 | Арча | 2,9 | 11,1 | 235,8 | 100,0 | - | 181,0 | 1 | 6 | 10 | 21 |
| 7 | Баулы | 2,1 | 8,0 | 170,8 | 83,0 | - | 224,9 | - | 4 | 7 | 15 |
| 8 | Биләр | 4,6 | 17,5 | 373,0 | 96,0 | - | 290,0 | 1 | 9 | 16 | 33 |
| 9 | Болгар | 1,7 | 6,5 | 137,7 | 10,0 | - | 63,0 | 1 | 3 | 6 | 12 |
| 10 | Бөгелмә | 4,0 | 15,2 | 324,1 | 169,0 | - | 197,0 | 1 | 8 | 14 | 28 |
| 11 | Буа | 1,7 | 6,4 | 136,8 | 30,0 | - | 144,0 | - | 3 | 6 | 12 |
| 12 | Алабуга | 2,6 | 10,9 | 211,6 | 149,0 | - | 110,0 | 1 | 5 | 9 | 19 |
| 13 | Зәй | 5,3 | 19,3 | 432,3 | 36,0 | - | 165,0 | 6 | 11 | 19 | 38 |
| 14 | Зеленодольск | 2,4 | 9,1 | 193,4 | 199,0 | 3 | 213,0 | 2 | 6 | 8 | 17 |
| 15 | Ары | 1,5 | 5,9 | 125,0 | 198,2 | 1 | 85,0 | 1 | 3 | 5 | 11 |
| 16 | Кайбыч | 2,3 | 9,7 | 185,2 | 105,0 | - | 120,0 | 2 | 5 | 8 | 16 |
| 17 | Кәләй | 3,7 | 14,3 | 303,2 | 20,0 | - | 70,0 | 3 | 8 | 13 | 27 |
| 18 | Кама | 4,9 | 18,8 | 399,5 | 100,0 | 1 | 171,0 | 3 | 10 | 18 | 35 |
| 19 | Кызыл Йолдыз | 3,8 | 14,7 | 312,0 | 13,0 | - | 98,0 | 2 | 8 | 14 | 27 |
| 20 | Лаеш | 3,0 | 11,6 | 246,2 | 149,0 | 1 | 239,0 | 2 | 6 | 11 | 22 |
| 21 | Лениногорск | 4,8 | 19,4 | 390,6 | 50,0 | - | 134,0 | 3 | 10 | 17 | 34 |
| 22 | Лубян | 1,2 | 4,5 | 95,7 | 10,0 | 2 | 34,0 | - | 2 | 4 | 8 |
| 23 | Мамадыш | 4,3 | 16,5 | 351,2 | 160,0 | 1 | 140,0 | 2 | 9 | 15 | 31 |
| 24 | Минзәлә | 6,5 | 25,0 | 531,8 | 30,0 | - | 273,0 | 1 | 13 | 23 | 47 |
| 25 | Түбән Кама | 3,9 | 15,0 | 319,5 | 81,0 | 1 | 290,0 | 2 | 8 | 14 | 28 |
| 26 | Нурлат | 5,6 | 19,8 | 654,7 | 118,0 | 1 | 120,0 | 1 | 16 | 29 | 56 |
| 27 | Идел буе | 2,5 | 9,7 | 205,6 | 35,0 | - | 86,0 | 6 | 5 | 9 | 18 |
| 28 | Шәһәр яны | 5,0 | 16,0 | 213,5 | 119,0 | 2 | 224,5 | 1 | 5 | 12 | 18 |
| 29 | Саба | 5,5 | 20,9 | 444,7 | 36,0 | 1 | 92,0 | 2 | 11 | 19 | 39 |
| 30 | Тәтеш | 3,4 | 14,9 | 274,9 | 20,0 | - | 122,0 | 1 | 7 | 12 | 24 |
| 31 | Чирмешән | 3,3 | 12,6 | 269,0 | 30,0 | - | 123,0 | 4 | 7 | 12 | 24 |
| Урманчылыклар буенча барлыгы | | 111,3 | 426,5 | 9075,9 | 2395,2 | 16 | 4806,9 | 55 | 225 | 398 | 794 |

# 2026 елга урманчылыклар буенча проектлана торган чаралар күләме

| Т/с | Урманчылык атамасы | Урманнарны янгыннардан саклау өчен билгеләнгән урман юллары төзү, км | Урманнарны янгыннан саклау өчен билгеләнгән урман юлларын карап тоту, км | Урманнарны янгыннардан саклау өчен билгеләнгән урман юлларын эксплуатацияләү, км | Янгынга каршы минераллаштырылган полосалар урнаштыру, км | Янгын күзәтчелеге пунктларын (каланчалар, мачталар, павильоннар һәм башка күзәтү пунктлары), янгынга каршы инвентарь туплау пунктларын төзү, карап тоту һәм эксплуатацияләү, данә | Янгынга каршы минераллаштырылган полосаларны чистарту һәм аларны яңарту, км | Янгынга каршы сулыкларны һәм су белән тәэмин итү чыганакларына килү юлларын эксплуатацияләү, данә | Россия Федерациясе Урман кодексының 11 статьясы нигезендә урманнарда гражданнар ял итә торган зоналарны әзерләү, данә | Шлагбаумнар кую һәм эксплуатацияләү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, урманнарда гражданнарның булуын чикләүне тәэмин итәрлек киртәләр кору, данә | Урманнарда янгын куркынычсызлыгы чаралары турында мәгълүматы булган стендлар һәм башка тамгалар урнаштыру, данә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Әгерҗе | 4,1 | 15,7 | 339,2 | 100,0 | 2 | 235,0 | 1 | 8 | 15 | 29 |
| 2 | Азнакай | 4,1 | 15,9 | 342,5 | 20,0 | - | 119,5 | 2 | 8 | 15 | 30 |
| 3 | Аксубай | 2,7 | 11,3 | 221,5 | 39,0 | - | 185,0 | 1 | 5 | 10 | 19 |
| 4 | Әлки | 3,4 | 13,0 | 280,9 | 50,0 | - | 89,0 | 2 | 7 | 12 | 24 |
| 5 | Әлмәт | 4,5 | 17,3 | 372,8 | 40,0 | - | 169,0 | - | 9 | 16 | 32 |
| 6 | Арча | 2,9 | 11,1 | 238,7 | 100,0 | - | 181,0 | 1 | 6 | 10 | 21 |
| 7 | Баулы | 2,1 | 8,0 | 172,9 | 83,0 | - | 224,9 | - | 4 | 7 | 15 |
| 8 | Биләр | 4,6 | 17,5 | 377,6 | 96,0 | - | 290,0 | 1 | 9 | 16 | 33 |
| 9 | Болгар | 1,7 | 6,5 | 139,4 | 10,0 | - | 63,0 | 1 | 3 | 6 | 12 |
| 10 | Бөгелмә | 4,0 | 15,2 | 328,1 | 169,0 | - | 197,0 | 1 | 8 | 14 | 28 |
| 11 | Буа | 1,7 | 6,4 | 138,5 | 30,0 | - | 144,0 | - | 3 | 6 | 12 |
| 12 | Алабуга | 2,6 | 10,9 | 214,2 | 149,0 | - | 110,0 | 1 | 5 | 9 | 19 |
| 13 | Зәй | 5,3 | 19,3 | 437,6 | 36,0 | - | 165,0 | 6 | 11 | 19 | 38 |
| 14 | Зеленодольск | 2,4 | 9,1 | 195,8 | 199,0 | 3 | 213,0 | 2 | 6 | 8 | 17 |
| 15 | Ары | 1,5 | 5,9 | 126,5 | 198,2 | 1 | 85,0 | 1 | 3 | 5 | 11 |
| 16 | Кайбыч | 2,3 | 9,7 | 187,5 | 105,0 | - | 120,0 | 2 | 5 | 8 | 16 |
| 17 | Кәләй | 3,7 | 14,3 | 306,9 | 20,0 | - | 70,0 | 3 | 8 | 13 | 27 |
| 18 | Кама | 4,9 | 18,8 | 404,4 | 100,0 | 1 | 171,0 | 3 | 10 | 18 | 35 |
| 19 | Кызыл Йолдыз | 3,8 | 14,7 | 315,8 | 13,0 | - | 98,0 | 2 | 8 | 14 | 27 |
| 20 | Лаеш | 3,0 | 11,6 | 249,2 | 149,0 | 1 | 239,0 | 2 | 6 | 11 | 22 |
| 21 | Лениногорск | 4,8 | 19,4 | 395,4 | 50,0 | - | 134,0 | 3 | 10 | 17 | 34 |
| 22 | Лубян | 1,2 | 4,5 | 96,9 | 10,0 | 2 | 34,0 | - | 2 | 4 | 8 |
| 23 | Мамадыш | 4,3 | 16,5 | 355,5 | 160,0 | 1 | 140,0 | 2 | 9 | 15 | 31 |
| 24 | Минзәлә | 6,5 | 25,0 | 538,3 | 30,0 | - | 273,0 | 1 | 13 | 23 | 47 |
| 25 | Түбән Кама | 3,9 | 15,0 | 323,4 | 81,0 | 1 | 290,0 | 2 | 8 | 14 | 28 |
| 26 | Нурлат | 5,6 | 19,8 | 660,3 | 118,0 | 1 | 120,0 | 1 | 16 | 29 | 56 |
| 27 | Идел буе | 2,5 | 9,7 | 208,1 | 35,0 | - | 86,0 | 6 | 5 | 9 | 18 |
| 28 | Шәһәр яны | 5,0 | 16,0 | 218,5 | 119,0 | 2 | 224,5 | 1 | 5 | 12 | 18 |
| 29 | Саба | 5,5 | 20,9 | 450,2 | 36,0 | 1 | 92,0 | 2 | 11 | 19 | 39 |
| 30 | Тәтеш | 3,4 | 14,9 | 278,3 | 20,0 | - | 122,0 | 1 | 7 | 12 | 24 |
| 31 | Чирмешән | 3,3 | 12,6 | 272,3 | 30,0 | - | 123,0 | 4 | 7 | 12 | 24 |
| Урманчылыклар буенча барлыгы | | 111,3 | 426,5 | 9187,2 | 2395,2 | 16 | 4806,9 | 55 | 225 | 398 | 794 |

# 2027 елга урманчылыклар буенча проектлана торган чаралар күләме

| Т/с | Урманчылык атамасы | Урманнарны янгыннардан саклау өчен билгеләнгән урман юллары төзү, км | Урманнарны янгыннан саклау өчен билгеләнгән урман юлларын карап тоту, км | Урманнарны янгыннардан саклау өчен билгеләнгән урман юлларын эксплуатацияләү, км | Янгынга каршы минераллаштырылган полосалар урнаштыру, км | Янгын күзәтчелеге пунктларын (каланчалар, мачталар, павильоннар һәм башка күзәтү пунктлары), янгынга каршы инвентарь туплау пунктларын төзү, карап тоту һәм эксплуатацияләү, данә | Янгынга каршы минераллаштырылган полосаларны чистарту һәм аларны яңарту, км | Янгынга каршы сулыкларны һәм су белән тәэмин итү чыганакларына килү юлларын эксплуатацияләү, данә | Россия Федерациясе Урман кодексының 11 статьясы нигезендә урманнарда гражданнар ял итә торган зоналарны әзерләү, данә | Шлагбаумнар кую һәм эксплуатацияләү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, урманнарда гражданнарның булуын чикләүне тәэмин итәрлек киртәләр кору, данә | Урманнарда янгын куркынычсызлыгы чаралары турында мәгълүматы булган стендлар һәм башка тамгалар урнаштыру, данә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Әгерҗе | 4,1 | 15,7 | 343,3 | 100,0 | 2 | 235,0 | 1 | 8 | 15 | 29 |
| 2 | Азнакай | 4,1 | 15,9 | 346,6 | 20,0 | - | 119,5 | 2 | 8 | 15 | 30 |
| 3 | Аксубай | 2,7 | 11,3 | 224,2 | 39,0 | - | 185,0 | 1 | 5 | 10 | 19 |
| 4 | Әлки | 3,4 | 13,0 | 284,3 | 50,0 | - | 89,0 | 2 | 7 | 12 | 24 |
| 5 | Әлмәт | 4,5 | 17,3 | 377,3 | 40,0 | - | 169,0 | - | 9 | 16 | 32 |
| 6 | Арча | 2,9 | 11,1 | 241,6 | 100,0 | - | 181,0 | 1 | 6 | 10 | 21 |
| 7 | Баулы | 2,1 | 8,0 | 175,0 | 83,0 | - | 224,9 | - | 4 | 7 | 15 |
| 8 | Биләр | 4,6 | 17,5 | 382,2 | 96,0 | - | 290,0 | 1 | 9 | 16 | 33 |
| 9 | Болгар | 1,7 | 6,5 | 141,1 | 10,0 | - | 63,0 | 1 | 3 | 6 | 12 |
| 10 | Бөгелмә | 4,0 | 15,2 | 332,1 | 169,0 | - | 197,0 | 1 | 8 | 14 | 28 |
| 11 | Буа | 1,7 | 6,4 | 140,2 | 30,0 | - | 144,0 | - | 3 | 6 | 12 |
| 12 | Алабуга | 2,6 | 10,9 | 216,8 | 149,0 | - | 110,0 | 1 | 5 | 9 | 19 |
| 13 | Зәй | 5,3 | 19,3 | 442,9 | 36,0 | - | 165,0 | 6 | 11 | 19 | 38 |
| 14 | Зеленодольск | 2,4 | 9,1 | 198,2 | 199,0 | 3 | 213,0 | 2 | 6 | 8 | 17 |
| 15 | Ары | 1,5 | 5,9 | 128,0 | 198,2 | 1 | 125,0 | 1 | 3 | 5 | 11 |
| 16 | Кайбыч | 2,3 | 9,7 | 189,8 | 105,0 | - | 120,0 | 2 | 5 | 8 | 16 |
| 17 | Кәләй | 3,7 | 14,3 | 310,6 | 20,0 | - | 97,5 | 3 | 8 | 13 | 27 |
| 18 | Кама | 4,9 | 18,8 | 409,3 | 100,0 | 1 | 171,0 | 3 | 10 | 18 | 35 |
| 19 | Кызыл Йолдыз | 3,8 | 14,7 | 319,6 | 13,0 | - | 124,0 | 2 | 8 | 14 | 27 |
| 20 | Лаеш | 3,0 | 11,6 | 252,2 | 149,0 | 1 | 239,0 | 2 | 6 | 11 | 22 |
| 21 | Лениногорск | 4,8 | 19,4 | 400,2 | 50,0 | - | 134,0 | 3 | 10 | 17 | 34 |
| 22 | Лубян | 1,2 | 4,5 | 98,1 | 10,0 | 2 | 34,0 | - | 2 | 4 | 8 |
| 23 | Мамадыш | 4,3 | 16,5 | 359,8 | 160,0 | 1 | 140,0 | 2 | 9 | 15 | 31 |
| 24 | Минзәлә | 6,5 | 25,0 | 544,8 | 30,0 | - | 273,0 | 1 | 13 | 23 | 47 |
| 25 | Түбән Кама | 3,9 | 15,0 | 327,3 | 81,0 | 1 | 290,0 | 2 | 8 | 14 | 28 |
| 26 | Нурлат | 5,6 | 19,8 | 665,9 | 118,0 | 1 | 120,0 | 1 | 16 | 29 | 56 |
| 27 | Идел буе | 2,5 | 9,7 | 210,6 | 35,0 | - | 86,0 | 6 | 5 | 9 | 18 |
| 28 | Шәһәр яны | 5,0 | 16,0 | 223,5 | 119,0 | 2 | 292,0 | 1 | 5 | 12 | 18 |
| 29 | Саба | 5,5 | 20,9 | 455,7 | 36,0 | 1 | 92,0 | 2 | 11 | 19 | 39 |
| 30 | Тәтеш | 3,4 | 14,9 | 281,7 | 20,0 | - | 122,0 | 1 | 7 | 12 | 24 |
| 31 | Чирмешән | 3,3 | 12,6 | 275,6 | 30,0 | - | 123,0 | 4 | 7 | 12 | 24 |
| Урманчылыклар буенча барлыгы | | 111,3 | 426,5 | 9298,5 | 2395,2 | 16 | 4967,9 | 55 | 225 | 398 | 794 |

# 2028 елга урманчылыклар буенча проектлана торган чаралар күләме

